МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.11.2020 г. Казань № под-1250/20

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 30 июлендәге под-1073/19 номерлы боерыгы белән расланган Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 30 июлендәге под-1073/19 номерлы боерыгы белән расланган Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны

имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының
10.07.2019 № пдо-1043/19 боерыгы
( Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының
25.11.2020 № пдо-1257/20 боерыгы
редакциясендә) белән расланды

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын, тәртибен һәм гамәлләр (административ процедуралар) эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләгән, аларны опекага (попечительлеккә) яисә тәрбиягә бала ала торган гаиләләргә кабул итәргә теләгән Россия Федерациясе гражданнары;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләр булган очракта, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләгән Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт банкының төбәк операторы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

«Уллыкка (кызлыкка) алу, опека һәм попечительлек республика үзәге» ДКУ (алга таба – Үзәк) Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү буенча ярдәм күрсәтә.

Россия Федерациясе гражданнары Министрлыкка турыдан-туры (шәхсән) мөрәҗәгать итә.

Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башка тәртип билгеләнмәгән булса, Министрлыкка шәхсән яки чит ил оешмалары вәкиллекләре аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3 йорт, 205, 207 кабинетлар.

Үзәкнең урнашу урыны: Казан шәһәре, Социалистик урамы, 5.

Министрлыкның эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.30 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Үзәкнең эш графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, көн саен 8.30 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Министрлык телефоны: 8 (843) 294-95-66.

Үзәк телефоннары: 533-00-84, 533-00-83; 533-00-82; 533-00-79; факс: 533-00-81, 533-00-84. Казан коды: 843.

1.3.3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.mon.tatarstan.ru.

Үзәкнең электрон почта адресы (e-mail): children_kazan@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендлары аша.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә оештырылган интернет-сайтта (алга таба – Интернет-сайт): www.usynovite.ru.

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә;

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, рәсми сайтының адресы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче белән эшләү өчен Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларында һәм Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

балалар турында төбәк белешмәләр банкы – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, Россия Федерациясенең берәр субъекты территориясендә яши торган һәм опека һәм попечительлек органы тарафыннан мондый балалар фактик булган урын буенча гаиләгә тәрбиягә урнаштырылмаган балаларны беренчел исәпкә алу һәм алар турында документлаштырылган мәгълүматларны, шулай ук балаларны үз гаиләләренә тәрбиягә алырга теләгән гражданнар, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукында чикләнгән гражданнар, үзләренә йөкләнгән законлы бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән, әгәр уллыкка (кызлыкка) алу суд тарафыннан алар гаебе белән гамәлдән чыгарылган булса, элеккеге уллыкка (кызлыкка) алучылар турында документлаштырылган мәгълүматларны үз эченә алган балалар турында дәүләт белешмәләр банкының бер өлеше;

балалар турында дәүләт белешмәләр банкының төбәк операторы (алга таба – төбәк операторы) – Россия Федерациясе Гаилә кодексының 122 статьясында билгеләнгән очракларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тәрбиягә гаиләләргә урнаштыруны оештыра торган Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану | Россия Федерациясе Гаилә кодексының 122 статьясы (алга таба – РФ Гаилә кодексы);<br>«Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы турында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон);<br>Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибе Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2020 елның 15 июнендәге 300 номерлы боерыгы белән расланган (алга таба – Тәртип) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 44-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы;<br>Тәртип |

| | | |
|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән һәм балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан балалар турында мәгълүматлар алу өчен мөрәҗәгать иткән зат турындагы мәгълүматларны балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертү (кертүдән баш тарту)<br>Мөрәҗәгать итүчегә балалар турында төбәк белешмәләр банкында мәгълүматлары булган балалар хакында сорала торган документлаштырылган мәгълүматны бирү (бирүдән баш тарту)<br>Бала янына бару өчен юллама бирү. | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Тәртипнең 34, 44 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны тапшыру (җибәрү) срогы | Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән һәм балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан балалар турында мәгълүматлар алу өчен мөрәҗәгать иткән зат турындагы мәгълүматларны балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертү (кертүдән баш тарту) гариза алынган көннән башлап 3 көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүчегә балалар турында төбәк белешмәләр банкында мәгълүматлары булган балалар хакында сорала торган документлаштырылган мәгълүматны бирү | 44-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы;<br>Тәртипнең 34, 44 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | (бирүдән баш тарту) гариза алынган көннән башлап 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Россия Федерациясе гражданины белгечкә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә һәм түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча баланы (балаларны) үз гаиләсенә тәрбиягә алу теләге турында һәм аны, аның теләкләренә туры килә торган, балалар турында исәптә булган белешмәләр белән таныштыру гозере белән гариза;<br>б) әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән форма буенча гражданин анкетасының тутырылган 1 бүлеге;<br>2. Россия Федерациясе гражданины, аның тарафыннан баланы уллыкка (кызлыкка) алуны рәсмиләштергән вакытта башка дәүләткә чыгып киткән очракта (эшкә яки башка сәбәпләр буенча), 1 пунктта күрсәтелгән документлардан тыш түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) әлеге Регламентның 5 нче һәм 6 нчы кушымталарында китерелгән формалар буенча әлеге дәүләтнең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән, аның яшәеш шартлары һәм уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәеш шартларына һәм аны тәрбияләүгә карата һәм уллыкка (кызлыкка) алуны рәсмиләштерү вакытына ул яшәгән территория дәүләтенә килү буенча Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә аны консуллык исәбенә кую буенча контрольлекне гамәлгә ашыру турында бәяләмә; | 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Тәртипнең 32-33; 39-41 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | б) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән документларны әзерләү буенча компетентлы орган вәкаләтләрен раслый торган чит ил оешмасы лицензиясенең (яисә чит ил дәүләте законнарында билгеләнгән башка документ) күчермәсе.<br>Документлар, әгәр Россия Федерациясе законнарында яки Россия Федерациясе халыкара килешүендә башкача каралмаган булса, билгеләнгән тәртиптә легальләштерелгән, рус теленә тәрҗемә ителгән булырга тиеш һәм тәрҗемә Россия гражданины яшәгән урындагы дәүләтнең консуллык учреждениесендә яки Россия Федерациясенең дипломатик вәкиллегендә яисә Россия Федерациясе территориясендә нотариус тарафыннан таныкланган булырга тиеш.<br>Документлар аларны биргән көннән алып ел дәвамында карап тикшерүгә кабул ителә. Әгәр чит ил дәүләте законнарында документларның башка гамәлдә булу срогы каралган булса, алар тиешле дәүләт законнары белән билгеләнгән срок эчендә карала ала.<br>3. Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданины, чит ил гражданины яисә гражданлыгы булмаган зат (алга таба – 3 пунктта күрсәтелгән гражданин) түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча баланы (балаларны) үз гаиләсенә тәрбиягә алу теләге турында һәм аны, аның теләкләренә туры килә торган, балалар турында исәптә булган белешмәләр белән | |

| | | |
|---|---|---|
| | таныштыру гозере белән гариза;<br>б) әлеге Регламентның 3 нче кушымтасыда китерелгән форма буенча гражданин анкетасының тутырылган 1 бүлеге;<br>в) үзе уллыкка (кызлыкка) алган баланы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнары булып торучы һәм чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны Россия Федерациясенең консуллык учреждениеләрендә исәпкә кую кагыйдәләре (алга таба – 275 номерлы кагыйдәләр) нигезендә Россия Федерациясенең тиешле консуллык учреждениесендә исәпкә кую буенча әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән форма буенча исәпкә кую йөкләмәсе;<br>г) әлеге Регламентка 8 нче кушымтада китерелгән форма буенча уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү өчен мөмкинлек бирү йөкләмәсе;<br>д) 3 пунктта күрсәтелгән һәм Россия Федерациясендә шул сыйфатта таныла торган гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;<br>е) ул гражданин булып торган дәүләтнең компетентлы органыннан аның яшәеш шартлары һәм уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә (даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яши торган Россия Федерациясе гражданины яисә гражданлыгы булмаган зат өчен – даими яшәү урыны булган дәүләтнең компетентлы | |

| | | |
|---|---|---|
| | органыннан). Бәяләмәгә аның гаиләсе турында фотоматериаллар теркәлә;<br>ж) 3 пунктта күрсәтелгән гражданин яшәгән дәүләтнең компетентлы органының уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәеш шартларын контрольдә тоту һәм әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән форма буенча һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 4 ноябрендәге 654 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча чит ил органнары һәм оешмалары эшчәнлеге һәм аны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту турындагы нигезләмәнең 22 пунктында билгеләнгән тәртиптә уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләсендә баланың яшәеш һәм тәрбия шартлары турында хисаплар тапшырып тору йөкләмәсе. Уллыкка (кызлыкка) алган гаиләдә баланың яшәеш һәм тәрбия шартлары турындагы хисаплар әлеге Регламентка 9 нчы кушымтада китерелгән форма буенча тапшырыла;<br>з) 3 пунктта күрсәтелгән гражданин яши торган дәүләтенең компетентлы органының әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән форма буенча һәм 275 номерлы кагыйдәләрдә билгеләнгән срокларда уллыкка (кызлыкка) алынган баланы Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә исәпкә кую куюны контрольдә тоту йөкләмәсе;<br>и) уллыкка (кызлыкка) алу өчен кандидат булып торган гражданин дәүләтенең компетентлы органыннан ул гражданин булып торган дәүләт законнарында бер җенестәге затлар арасында | |

| | | |
|---|---|---|
| | төзелгән гаиләнең булмавын раслый торган документ (гаиләле булмаган зат мөрәҗәгать иткән очракта тапшырыла);<br>к) әлеге пунктның «е»-»и» пунктчаларында күрсәтелгән документларны әзерләү буенча компетентлы орган вәкаләтләрен раслаучы чит ил оешмасы лицензиясенең (яисә башка документның) күчермәсе;<br>л) мондый документларга карата чит ил дәүләте законнарында белдерелә торган таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән уллыкка (кызлыкка) алу буенча кандидатларны әзерләү узганлыгы турында таныклык яки башка документ күчермәсе;<br>м) мондый документларга карата чит ил дәүләте законнарында белдерелә торган таләпләр нигезендә уллыкка (кызлыкка) алу буенча кандидатларны әзерләү уздыруга нигез булган программа күчермәсе;<br>н) уллыкка (кызлыкка) алу буенча кандидатлар әзерләү узу турында документ биргән чит ил оешмасының гражданнарны шул рәвешле әзерләү һәм тиешле документ бирү хокукын раслый торган документ.<br>3 пунктта күрсәтелгән гражданин санап үтелгән документларны тапшыра:<br>а) төбәк операторына шәхсән;<br>б) Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча чит ил дәүләт органы яисә оешма вәкиллеге яисә Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга тиешле рөхсәт алган чит ил коммерциясез | |

| | | |
|---|---|---|
| | хөкүмәтнеке булмаган оешма вәкиллеге аша.<br>4. 3 пунктта күрсәтелгән гражданин, баланы уллыкка (кызлыкка) алган вакытта бер елдан артык вакытка башка дәүләткә чыгып киткән очракта (эшкә яки башка сәбәпләр аркасында), 3 пунктның «а»-»д», «и» һәм «л»-»н» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш, түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә һәм уллыкка (кызлыкка) алган баланың яшәеш һәм тәрбия шартларына контрольлекне гамәлгә ашыру һәм аны даими яшәү урыны булган дәүләткә кире әйләнеп кайтканнан соң Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә консуллык исәбенә кую турында әлеге дәүләтнең компетентлы органыннан бирелгән йөкләмә;<br>б) әлеге дәүләтнең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән, аның яшәеш шартлары һәм уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәеш шартларына һәм аны тәрбияләүгә карата һәм уллыкка (кызлыкка) алуны рәсмиләштерү вакытына ул яшәгән территория дәүләтенә килү буенча Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә аны консуллык исәбенә кую буенча контрольлекне гамәлгә ашыру турында бәяләмә;<br>в) әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән документларны әзерләү буенча компетентлы орган вәкаләтләрен раслаучы чит ил оешмасы лицензиясенең (яисә башка документның) күчермәсе.<br>5. Гражданины булып тормаган дәүләт территориясендә даими рәвештә яши торган чит | |

| | | |
|---|---|---|
| | ил гражданины 3 пунктның «а»-«д», «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш, 3 пунктның «е»-«з» һәм «к»-«н» пунктчаларында күрсәтелгән, аның даими яшәү урыны булган дәүләтнең компетентлы органыннан бирелгән документларны тапшыра. Шулай ук, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 1 пунктының 9-11 пунктчаларында күрсәтелгән шартлар булмавын раслый торган, гражданины булып торган дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән документны тапшыра.<br>6. 3 пунктта күрсәтелгән, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләгән, аның туганы булып торган гражданин, 3-5 пунктларда каралган документлардан тыш, опека һәм попечительлек органнарына уллыкка (кызлыкка) алынучы бала белән туганлык фактын раслаучы документларны тапшыра.<br>3-5 пунктлар нигезендә тапшырылган барлык документлар, әгәр Россия Федерациясе законнарында яки Россия Федерациясе халыкара килешүендә башкача каралмаган булса, билгеләнгән тәртиптә легальләштерелгән, рус теленә тәрҗемә ителгән булырга тиеш һәм тәрҗемә чит ил гражданины яшәгән урындагы дәүләтнең консуллык учреждениесендә яки Россия Федерациясенең дипломатик вәкиллегендә яисә Россия Федерациясе территориясендә нотариус тарафыннан таныкланган булырга тиеш.<br>3 пунктның «а»-«г» пунктчаларында күрсәтелгән документлар ел дәвамында аларны төзү | |

| | | |
|---|---|---|
| | датасыннан соң, ә 3 пунктның «е»-«к», 4 пунктның «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгән документлар аларны биргәннән соң ел дәвамында карап тикшерүгә алына.<br>Әгәр чит ил дәүләте законнарында 3 пунктның «е»-«н» пунктчаларында һәм 4 пунктның «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгән документларның башка гамәлдә булу срогы каралган булса, алар тиешле дәүләт законнарында билгеләнгән вакыт эчендә карала ала<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан) | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) гражданинның хосусый шәхси счетының (СНИЛС) иминият номеры – Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнарында;<br>2) Гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органыннан бирелгән гражданинның уллыкка (кызлыкка) алучы, опекун (попечитель) була алу мөмкинлеге турындагы бәяләмә. Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу | Тәртип<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында | |

| | | |
|---|---|---|
| | каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>- тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләр булуы;<br>- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасы тапшырылганда | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре: мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар эчтәлегенең яки рәсмиләштерелүенең әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтелүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза тапшырылган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, объектлардан файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:<br>а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;<br>б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясы;<br>Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтелә торган объектлардан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар өчен файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук бу вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 9 ноябрендәге 1309 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;<br>г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу мөмкинлеге;<br>д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;<br>е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;<br>ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә | |

| | | |
|---|---|---|
| | торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, хезмәтләр күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.<br>Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:<br>а) объектка кергәндә Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән һәм контраст фонында эшләнгән оешма атамасы, оешманың эш графигы белән элмә librettaлар, бина планы булуы;<br>б) инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>в) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, хезмәт күрсәтү;<br>г) массакүләм чаралар үткәрү өчен билгеләнгән биналарның берсендә индукцион петельләр һәм тавыш көчәйтү аппаратурасы булу;<br>д) хезмәт күрсәтүче орган һәм оешманың рәсми сайтын күрү сәләте начар булган (начар күрүчеләр) өчен җайлаштыру;<br>е) хезмәт күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга мәгариф өлкәсендәге хезмәттән файдалануга һәм объектларны башка затлар белән беррәттән | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда кирәкле башка ярдәмне күрсәтү. 2016 елның 1 июленнән соң шулай ук капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керәп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалана алу (шул исәптән тулы күләмендә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| | итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозулар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен кирәкле документлар тапшырылганда мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән үзара хезмәттәшлек итү саны, турыдан-туры булганда, бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан mon.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралар үтәлешен үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) гариза белән документларны кабул итү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән һәм балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан балалар турында мәгълүматлар алу өчен мөрәҗәгать иткән зат турындагы мәгълүматларны балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертү (кертүдән баш тарту);

5) мөрәҗәгать итүчегә балалар турында төбәк белешмәләр банкында мәгълүматлары булган балалар хакында сорала торган документлаштырылган мәгълүматны бирү (бирүдән баш тарту);

6) баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче мөрәҗәгать итүчеләргә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала янына бару өчен юллама бирү;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта аша, Министрлыкның рәсми сайтының Интернет-кабул итү системасы (http://www.mon.tatar.ru) аша һәм (яисә) хат белән дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

Министрлык хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультация бирә, гариза бланкын бирә һәм, кирәк булганда, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә, техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, кисәтүләр.

3.3. Гариза белән документларны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, кәгазьдәге гаризаны шәхсән үзе Министрлыкка тапшыра (җибәрә). Мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны Министрлыкка тапшыру административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

3.3.2. Министрлыкның опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге белгече (алга таба – Бүлек белгече) тапшырылган документларны асылы буенча карый:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели, шул исәптән шәхесне раслаучы документны тикшерә;

гражданин тарафыннан тапшырылган барлык кирәкле документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен һәм булуын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече, кире кайтару сәбәпләрен язмача нигезләп, мөрәҗәгать итүчегә документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза яки кире кайтару сәбәпләрен язмача нигезләп, мөрәҗәгать итүчегә документларны кире кайтару.

3.3.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече, мөрәҗәгать итүчегә, сәбәпләрен күрсәтеп, ул тапшырган документларны кире кайтара.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларны карау, балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертүдән баш тарту сәбәпләрен язма рәвештә күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә документларны кире кайтару.

Әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.3 пунктларында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар алынган көннән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Министрлык хезмәткәре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

гражданинның хосусый шәхси счетының иминият номеры турында белешмәләр бирү хакында – (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнарына);

гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органыннан бирелгән гражданинның уллыкка (кызлыкка) алучы, опекун (попечитель) була алу мөмкинлеге турындагы бәяләмә бирү хакында

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче оешма белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгать нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) Министрлыкка бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.5. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән һәм балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан балалар турында мәгълүматлар алу өчен мөрәҗәгать иткән зат турындагы мәгълүматларны балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертү (кертүдән баш тарту)

3.5.1. Бүлек белгече, әлеге Регламентның 3.4.1-3.4.2 пунктлары нигезендә алынган белешмәләрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны карый.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән һәм балалар турында төбәк белешмәләр банкыннан балалар турында мәгълүмат алу өчен мөрәҗәгать иткән зат турындагы мәгълүматларны балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертә.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече, мөрәҗәгать итүчегә, сәбәпләрен күрсәтеп, ул тапшырган документларны кире кайтара.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларны, гражданин турындагы белешмәләрне карау, балалар турында төбәк белешмәләр банкына мәгълүматлар кертү, балалар турында төбәк белешмәләр банкына кертүдән баш тарту сәбәпләрен язмача күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә документларны кайтарып бирү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза алынган датадан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә балалар турында төбәк белешмәләр банкында мәгълүматлары булган балалар хакында сорала торган документлаштырылган мәгълүматны бирү (бирүдән баш тарту)

3.6.2. Гражданинны балалар турында төбәк белешмәләр банкына керткәннән соң, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүче теләкләренә туры килә торган балаларның анкеталарын сайлап ала, танышып чыгу өчен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә аның теләкләренә туры килә торган балаларның анкеталарын бирү

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач алты көн дәвамында башкарыла.

3.7. Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче мөрәҗәгать итүчеләргә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала янына бару өчен юллама бирү.

3.7.1. Бүлек белгече, гражданин анкеталары белән танышып чыккан бала янына баруга риза булган очракта, әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасында китерелгән форма буенча әлеге баланы карау өчен юллама проектын әзерли һәм имзалау өчен министр урынбасарына җибәрә.

3.7.2. Министр урынбасары (ул вәкаләт биргән зат) юлламаны имзалый һәм Министрлык белгеченә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче анкета белешмәләре белән танышып чыккан бала янына баруга ризалык белдергән вакыттан башлап, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла,

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасары имзалаган юллама.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентка 13 нче кушымта нигезендәге форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрелә.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә терки һәм аларны Министрлыкка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Министрлыкка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Министрлык документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Министрлыкка техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүчедән җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру;
- эшчәнлек алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;
- дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатенә бәйле мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшырылырга мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамаган өчен җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда мөрәҗәгать итүчедән,

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан http://www.mon.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның, дәүләт хезмәте күрсәткән Министрлыктагы вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка формаларда да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта**

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен һәм аны күрсәткәндә агымдагы контрольлек өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 294-95-90 | Ilsur.Hadiullin@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 294-96-02 | Alsu.Asadullina@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге башлыгы | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы | 264-77-20 | Andrey.Vybornov@tatar.ru |

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта**

________________________________________________
(дәүләт хакимияте органының исеме)
________________________________________________
________________________________________________
кемнән __________________________________________
(гражданинның фамилиясе, исеме, ата исеме
(ата исеме – булган очракта)
________________________________________________
яши торган адресы: ______________________________
________________________________________________

**Гражданинның үз гаиләсенә баланы (балаларны) тәрбиягә алырга теләве һәм исәптә торучы, аның теләкләренә туры килә торган балалар турындагы белешмәләр белән таныштыру үтенече белән**

**ГАРИЗА**

Мин (Без),__________________________________________________________________
(ирнең яисә хатынның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Гражданлыгы____________________паспорт: серия____________№ __________________________
______________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
һәм__________________________________________________________________________
(ир белән хатынның икенчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(булган очракта) – булган очракта яисә ир белән хатын икесе бергә мөрәҗәгать иткән очракта)

Гражданлыгы____________________паспорт: серия__________________№ _____________________
______________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Баланы/балаларны __________ сайлап алуда булышлык күрсәтүегезне сорыйбыз (кирәклесе
(балалар саны)
астына сызарга)
уллыкка (кызлыкка) яки опекага (попечительлеккә) алуны рәсмиләштерү өчен (ассызыкларга кирәк), гражданин анкетасында күрсәтелгән теләкләр нигезендә опека һәм попечительлек органында, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль/төбәк белешмәләр банкында (кирәклесе астына сызарга) булган белешмәләр белән таныштыруны үтенәбез.

Баланы гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче гражданин турындагы персональ мәгълүматларны җыю нигезләре, максатлары һәм куллану тәртибе белән таныш. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкында минем (безнең) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза. Балалар турында җыелма мәгълүматны җибәрү тәртибе белән таныш.
Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала(лар) анкетасындагы конфиденциаль мәгълүмат(лар)ны фәкать баланы (балаларны) минем (безнең) гаиләгә тәрбиягә тапшыру мәсьәләсен хәл итү максатларында гына кулланырга сүз бирәм (бирәбез).

«_____»_____________20___ел _____________________ (имза(лар))

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта**

**Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алу теләге булган гражданинның**

## АНКЕТАСЫ

**1 нче бүлек** (гражданин тарафыннан тутырыла)*(1)
Гражданин турында мәгълүмат
(тутыру датасына)

______________________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Җенесе__________ Туган датасы_____________________________
(туган көне, ае, елы)
Туган урыны____________________________________________
(республика, край, өлкә, торак пункт)
Гражданлыгы____________________________________________
Гаилә хәле_____________________________________________
______________________________________________

Теркәлгән адресы_______________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
Яши торган адресы______________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
Элемтә өчен телефон номеры (факс)______________________
(шәһәрара кодны күрсәтеп)
Электрон почта адресы, булган очракта__________________
Шәхесне раслаучы документ______________________________
(документ төре)
серия____________________номер_________________________
______________________________________________
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
Хосусый шәхси счетның иминият номеры
(СНИЛС):_______________________________________

Уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә

(Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен - яшәеш шартлары һәм уллыкка (кызлыкка) алучы була алу мөмкинлеге турында бәяләмә) әзерләнде:_________________________________________

______________________________________________
(орган исеме)
датасы______________________номеры_____________________;
гражданин үз гаиләсенә кабул итәргә теләгән балалар саны______________

Гражданин үз гаиләсенә кабул итәргә теләгән бала (балалар) турында мәгълүмат *(2)
Җенесе____________яше______________ башлап _____ яшькә кадәр
Сәламәтлек торышы______________________________________

Тышкы кыяфәте: күз төсе____________________ чәч төсе________________________
Башка теләкләр_________________________________________________________
Гражданин үз гаиләсенә баланы тәрбиягә алырга теләгән төбәкләр *(3):

_________________________________________________________________________

«____»______________2________ел. гражданинның имзасы

**2 нче бүлек** (ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы операторы тарафыннан ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль/төбәк белешмәләр банкында тутырыла) *(4)

_______________________________________________________________________
(анкета номеры)*(5)

Исәпкә кую датасы__________________________________________________
(көне, ае, елы)

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль (төбәк) белешмәләр банкының гражданин турындагы мәгълүматларны документлаштырган хезмәткәренең фамилиясе

_______________________________________________________________________

**Гражданинга ул сайлап алган бала янына бару өчен бирелә торган ятим балалар оешмаларына юлламалар турында һәм алар тарафыннан кабул ителгән карар турында мәгълүмат**

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкында баланың анкета номеры________________________________________________
Юллама бирү датасы_________________________________________________
Баланы гаиләгә кабул итү турында карар яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мондый карар кабул итүдән баш тарту турында тамга

_________________________________________--

**Гражданин турында белешмәләрне исәпкә алуны туктату турында мәгълүмат**

Баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турында карар чыгару турында документ реквизитлары (суд карары, опека һәм попечительлек органы акты, тәрбиягә бала алган гаилә, патронат гаилә төзү турында килешү)

_______________________________________________________________________
(килешү төзелгән орган исеменнән карар чыгарган орган иseme)

_______________________________________________________________________

«____» _____________2____ел № _________
(карар чыгару датасы)

Гражданин турында белешмәләрне исәпкә алуны туктату сәбәбе__________________________

Исәпкә алу туктатылу датасы: «_____» _____________20_____ел.

______________________________

*(1) Шәхси характердагы гражданин турындагы белешмәләр шәхесне раслаучы документка туры килергә тиеш.

* (2) Берничә баланы уллыкка алырга теләү турында гариза биргән очракта, бүлекчә гражданин үз гаиләсенә алырга мөмкин булган һәр балага балалар санына тигез күләмдә тутырыла.

*(3) Төбәк операторына мөрәҗәгать иткәндә, төбәкләрнең исеме урынына муниципаль берәмлекләрнең исемнәре күрсәтелә.

*(4) Электрон рәвештә генә тутырыла.

*(5) Гаиләле гражданнарның анкеталары бер номерга ия.

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта**

**Форма**

Опека һәм попечительлек органы бланкы

**Гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органыннан бирелгән гражданинның уллыкка (кызлыкка) алучы *(1), опекун (попечитель)*(2) була алу мөмкинлеге турындагы бәяләмә**

Ирнең яисә хатынның фамилиясе, исеме, ата исеме (тулысынча, ата исеме - булган очракта) ________________

______________________________________________________________________

Туган көне:__________, теркәлү адресы:___________________

______________________________________________________________________

(почта индексын күрсәтеп)

Ир белән хатынның икенчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме (тулысынча, соңгысы - булган очракта) яисә ир белән хатын икесе дә мөрәҗәгать иткән очракта)___________________________________

______________________________________________________________________

Туган көне:_________, теркәлү адресы: ___________________

______________________________________________________________________

(почта индексын күрсәтеп)

Яши торган адресы:_________________________________________________

(почта

______________________________________________________________________

индексын күрсәтеп)

Гаиләгә сыйфатлама (составы, гаилә булып яшәү озынлыгы (икенче тапкыр гаилә кору очрагында, алдагы гаиләдәге балаларны күрсәтергә), балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, якын туганнар булуы һәм аларның баланы гаиләгә тәрбиягә алуга карата мөнәсәбәте, уллыкка (кызлыкка) опекунлыкка (попечительлеккә) алу, тәрбиягә алучы ата-ана, патронат тәрбиячеләр буенча кандидатның холык үзенчәлекләре); ир белән хатынның берәрсе тарафыннан баланы уллыкка (кызлыкка) алган очракта икенчесенең уллыкка (кызлыкка) алуга ризалыгын күрсәтергә, опека (попечительлек) билгеләнгән очракта – опекун (попечитель) булырга теләгән гражданин белән бергә яши торган, 10 яшенә җиткән балаларның фикерен исәпкә алып, барлык балигълык яшенә җиткән гаилә әгъзаларының баланы (балаларны) гаиләгә кабул итүгә ризалыгы).

______________________________________________________________________

Белеме һәм һөнәри эшчәнлеге_________________________________________

______________________________________________________________________

Сәламәтлек торышының характеристикасы (гомуми сәламәтлеге торышы, баланы гаиләгә тәрбиягә алырга комачаулаучы авырулары булмавы

______________________________________________________________________

Матди хәле (мөлкәте, хезмәт хакының күләме, башка керем төрләре, керем күләменең төбәктә билгеләнгән яшәү минимумына нисбәте)________________________________________

Гражданинда Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 1 пунктының 9 һәм 10 пунктчаларында һәм 146 статьясының 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән шартларның булмавын раслый торган белешмәләр

________________________

________________________________________________________________

Бала (бала) гаиләгә тәрбиягә алу өчен мотивлар________________

________________________________________________________________

Бала (балалар) кандидатурасы буенча теләкләр (балалар саны, җенесе, яше, сәламәтлек торышы һ.б.)__________________________________________

________________________________________________________________

Мөмкинлек / мөмкинлек булмавы турында бәяләмә_____________________________

________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче(ләр)нең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)) уллыкка (кызлыкка) яки опекунлыкка (попечительлеккә) кандидатлар була алу *(3):

________________________________________________________________

(гражданинның (гражданнарның) кандидат була алу мөмкинлеге/мөмкин булмавы турында карар)

________________________________________________________________

уллыкка (кызлыкка) яки опекунлыкка (попечительлеккә) алу

________________________________________________________________

гражданинның балаларның саны һәм сәламәтлеге торышына кагылышлы теләкләрен исәпкә алып кабул ителә, түбәндәге очракта

________________________________________________________________

уллыкка (кызлыкка) алу яки опекун (попечитель) булуга кандидат булу мөмкинлегенең булмавы турында карар кабул ителгән очракта, гражданинның уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) буенча кандидат була алу мөмкинлегенең булмавы турында карар кабул итүгә нигез булган норматив хокукый актларның нормаларын күрсәтеп, баш тарту сәбәпләре күрсәтелергә тиеш*(4))

________________________________________________________________

| ____________________ | ____________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| вазыйфа | имза | фамилиясе, исеме һәм ата исеме (булган очракта) |

мөһер урыны

________________________

*(1) Теркәлгән гаиләдә яшәүче гражданнарга бер бәяләмә рәсмиләштерелә.

*(2) Гаиләгә урнаштыруның сайланган формасына карап күрсәтелә. Әгәр бәяләмә берничә биттә рәсмиләштерелгән булса, битләр номерланырга, тегелергә һәм бәяләмә биргән орган мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

*(3) Гаиләгә урнаштыруның сайланган формасына карап күрсәтелә.

*(4) Гражданинның уллыкка (кызлыкка) алучы яки опекун (попечитель) буенча кандидат була алу мөмкинлегенең булмавы турында карар кабул итүгә нигез булган норматив хокукый актларның нормалары күрсәтелә.

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта**

**Форма**

Орган (оешма) бланкы

# ЙӨКЛӘМӘ

______________________________________________________________

(уллыкка алынганнан соң баланың яшәү һәм тәрбия шартларын контрольдә тоту

______________________________________________________________

буенча йөкләмә бирүче орган/оешма исеме)

уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшереп тору йөкләмәсен үз өстенә ала)__________________________________________

(уллыкка (кызлыкка) алуга кандидатларны фамилиясе, исеме,ата исеме (ата исеме – булган очракта)

______________________________________________________________,

яши торган адресы: ___________________________________________

__________________________________________һәм уллыкка (кызлыкка)

алучылар гаиләсендә баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турында хисаплар тапшырып торырга.

Хисаплар бала уллыкка (кызлыкка) алынган территория карый торган Россия Федерациясе субъектының тиешле башкарма хакимият органында/ уллыкка (кызлыкка) алу буенча чит ил оешмасы вәкиллеге аша төзеләчәк һәм тапшырып торылачак*

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(гражданнарга уллыкка (кызлыкка) алуда ярдәм күрсәтеләчәк

______________________________________________________________

чит ил оешмасы атамасы һәм аның адресы)

______________________________________________________________

Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә **:

беренче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 2 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 4 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;

икенче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергән көннән 5 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап судның уллыкка (кызлыкка) алу турындагы карары законлы көченә кергән көннән 7 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;

өченче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 11 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 13 нче ай тәмамланганчыга кадәр тапшырыла;

дүртенче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 23 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 25 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;
бишенче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 25 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 37 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;
Уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергәннән соң 3 ел узгач һәм бала балигълык яшенә җиткәнче баланың яшәү һәм тәрбия шартларына тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турында алдагы хисап төзелгән датадан соң 23 ай узып киткәч гамәлгә ашырыла. Баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турында хисап алдагы хисап төзелгәннән соң 25 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;
Хисаплар тиешле чит ил дәүләтенең дәүләт (рәсми) телендә тапшырыла;
Тапшырыла торган хисаплар, әгәр Россия Федерациясе законнарында яки Россия Федерациясенең халыкара килешүләрендә башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясе Консуллык уставы» 2010 елның 5 июлендәге 154-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә легальләштерелергә, шулай ук рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Шул ук вакытта тәрҗемә Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алучыларның яшәү урыны дәүләтендә яисә нотариуста раслана.
Хисапларга фотоматериаллар теркәлергә тиеш.
Тапшырылган хисапларда чистартылган, өстәп язылган урыннар, сызып ташланган сүзләр һәм башка төрле тзәтүләр, шулай ук аларның эчтәлеген бер мәгънәдә аңлау мөмкинлеген бирми торган башка төрле җитди бозулар булмаска тиеш.

| ______________ | ______________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (И.Фамилия) |

мөһер урыны

---

* Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча чит ил дәүләт органы яисә оешма вәкиллеге яисә Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга тиешле рөхсәт алган чит ил коммерциясез хөкүмәтнеке булмаган оешма вәкиллеге ярдәендә уллыкка (кызлыкка) алу гамәлгә ашырылган очракта гына күрсәтелә.
** Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 4 ноябрендәге 654 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча чит ил органнары һәм оешмалары эшчәнлеге турында һәм аларны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту турындагы нигезләмәнең 22 пункты (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 46, 4801; 2013, № 35, 4511 ст.).

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта**

**Форма**

Орган (оешма) бланкы

# ЙӨКЛӘМӘ

______________________________________________

(уллыкка (кызлыкка) алынган баланың Россия Федерациясе консуллык

______________________________________________

учреждениесендә исәпкә куелуын контрольдә тотарга йөкләмә бирүче орган/оешма исеме)

Россия Федерациясендә уллыкка алынган баланың исәпкә алынуын контрольдә тоту йөкләмәсен үз өстенә ала,

______________________________________________

(уллыкка (кызлыкка) алуга кандидатларны фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________,

яши торган адресы: ______________________________

______________________________________________,

исәпкә алу______________________________________

______________________________________________,

(консуллык учреждениесе исеме)

урнашкан адресы:_________________________________

(тиешле консуллык учреждениесенең исеме)

_______________ _______________ _______________________

(вазыйфа) (имза) (И.Фамилия)

мөһер урыны

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта**

**Форма**

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган
балалар турында дәүләт белешмәләр
банкы төбәк операторына

кемнән____________________________________
(гражданинның (гражданнарның) фамилиясе,
исеме, атасының исеме (булган очракта))
____________________________________
____________________________________

# ЙӨКЛӘМӘ

Мин (Без,_________________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), шәхес таныклый
торган документ(лар)ның реквизитлары)
__________________________________________________________________
_________________________________________________________________,
яши торган адрес:
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________,
мин (без) яши торган дәүләт территориясенә мин (без) уллыкка (кызлыкка) алган баланы алып кергән көннән башлап 3 айлык срокта аны исәпкә кую йөкләмәсен алам (алабыз), түбәндә ____________________________
_________________________________________________________________
(Россия Тышкы эшләр министрлыгы / консуллык учреждениесе исеме,
_________________________________________________________________,
гражданин(гражданнар)яши торган территориядә консуллык округы чикләрендә)

урнашкан адресы:___________________________________________
(тиешле консуллык учреждениесенең исеме)
_________________________________________________________________.

Уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү урыны үзгәргәндә бу хакта әлеге консуллык учреждениесенә хәбәр итәргә һәм баланы яңа яшәү урыны буенча Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә исәпкә кую йөкләмәсен үз өстемә алам (үз өстебезгә алабыз).

«_____»______________20___ел                    ____________________
(имза(лар))

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта**

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган
балалар турында дәүләт белешмәләр банкы
төбәк операторына

кемнән________________________________________________

Гражданинның (гражданнарның)
фамилиясе, исеме, ата исеме

____________________________________________________

# ЙӨКЛӘМӘ

Мин (Без),____________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), шәхес таныклый торган документ(лар)ның реквизитлары)

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________,

яши торган адрес:

________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________,

минем (безнең) яшәү урыны буенча компетентлы органнарга мин (без) баланы уллыкка (кызлыкка) алган урын буенча аның яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү мөмкинлеге бирүне йөкләмәсен үз өстемә алам.

Яшәү урыны үзгәргәндә, мин (без) уллыкка (кызлыкка) алган баланың яшәү һәм тәрбия шартларына контрольлек башкару йөкләмәсен биргән компетентлы органга бу хакта мәгълүмат җиткерергә, шулай ук компетентлы органга яңа яшәү урыны буенча уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү мөмкинлеген бирү йөкләмәсен үз өстебезгә алабыз.

Мин (без) Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләр белән риза булуыбыз хакында хәбәрдар:

беренче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 2 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 4 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;

икенче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергән көннән 5 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап судның уллыкка (кызлыкка) алу турындагы карары законлы көченә кергән көннән 7 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;

өченче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 11 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 13 нче ай тәмамланганчыга кадәр тапшырыла;

дүртенче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 23 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап

уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 25 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;
бишенче тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерү суд карары законлы көченә кергәннән соң 25 ай узгач башкарыла, баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турындагы хисап уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән соң 37 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;
Уллыкка (кызлыкка) алу турындагы суд карары законлы көченә кергәннән соң 3 ел узгач һәм бала балигъ лык яшенә җиткәнче баланың яшәү һәм тәрбия шартларына тикшерү баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турында алдагы хисап төзелгән датадан соң 23 ай узып киткәч гамәлгә ашырыла. Баланың яшәү һәм тәрбия шартлары турында хисап алдагы хисап төзелгәннән соң 25 айдан да соңга калмыйча тапшырыла.

«_______»____________20___ел

___________________
(имза (лар))

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта**

**Форма**

Хисап әзерләгән оешма бланкы.
Хисап төзү датасы

**Уллыкка (кызлыкка) алган гаиләдә баланың яшәү**

**һәм тәрбия шартлары турында**

**ХИСАП**

Уллыкка (кызлыкка) алынганнан соң баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
Баланың җенесе______________________________
Уллыкка (кызлыкка) алганнан соң баланың туган датасы
______________________
Уллыкка (кызлыкка) алу датасы______________________________
Уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карарының законлы көченә керү датасы _
______________________________
Уллыкка (кызлыкка) алынганчыга кадәр баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
Уллыкка (кызлыкка) алганчыга кадәр баланың туган датасы
______________________
Уллыкка (кызлыкка) алганчыга кадәр яшәү урыны (Россия Федерациясе субъекты)__________
Уллыкка (кызлыкка) алучыларның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта)
Баланың һәм уллыкка (кызлыкка) алучыларның яши торган адресы, телефоны______________________
Уллыкка (кызлыкка) алучыларның эш урыны, адресы, телефоны______________________
Тикшерү уздырган затның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), вазыйфасы______________________________
Тикшерү үткәрү датасы______________________________
Алдан уздырылган тикшерү датасы, кем тарафыннан уздырылган
______________________
Киләсе тикшерү датасы______________________________

**1. Бала ихтыяҗларын тәэмин итү.**

(Тикшерү вакытына төп ихтыяҗларга сыйфатлама бирергә һәм алар ничек канәгатьләндерелә, алдагы тикшерү барышында билгеләнгәннәрдән нәрсәләрнең эшләнгәнлеге (эшләнмәгәнлеге) турында чара күрергә).

Сәламәтлек: физик үсеш – буй үсеше, авырлыгы, проблемалар, күрелгән чаралар, ел саен үткәрелә торган медицина күзәтүен узу, прививкалар.

Белеме: уңышлары, проблемалары, аларның баланың яшенә туры килүе, белем бирү программаларын үзләштерү формасы, белем бирү оешмасының төре, өстәмә белем бирү (баланың нинди өстәмә белем бирү оешмаларына йөрүен күрсәтергә; баланың яшенә карап күрсәтелә).

Баланың сәләтен үстерүне тәэмин итү: баланың уеннардан, түгәрәкләрдән, спорттан файдалана алу мөмкинлеге.

Тышкы кыяфәте һәм социаль таләпләргә яраклаштырылуы: киемнең яшенә, җенесенә, мәдәниятенә, диненә туры килүе, шәхси гигиена, баланың төрле шартларда үз-үзен тотышы адекват булуы, уллыкка (кызлыкка) алучыларның киңәшләрен кабул итә алу-алмавы.

Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләре: киенү, мөстәкыйль туклану, социаль һәм көнкүреш проблемаларын хәл итү.

**2. Уллыкка (кызлыкка) алучыларның бала ихтыяҗларын тәэмин итә алу сәләте.**

Төп тәрбия: баланың төп ихтыяҗларын канәгатьләндерү – тукландыру, торак, гигиена, кием-салым белән тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтү.

Аның яше буенча баланың иминлеген тәэмин итү (көнкүрештә куркыныч предметлардан файдалану мөмкинлеге булмау).

Уллыкка (кызлыкка) алучылар бәйләнешне ничек чагылдыра, бала рухи җылылык алсын өчен таләп ителгән торыш бармы.

**3. Гаилә һәм тирә-юньдәге факторлар.**

Гаилә тарихы: хәзерге вакытта бала тормышына йогынты ясый гаилә тарихы – йортта кем яши һәм бу балага ничек йогынты ясый, хәзерге вакытта һәм элек гаилә составындагы үзгәрешләр, уллыкка (кызлыкка) алучыларның гражданлык статусы яки гаилә хәле үзгәрүе турында, гаилә кыйммәтләре һәм традицияләр, уллыкка (кызлыкка) алучыларның туганнар белән һәм үзара мөнәсәбәтләр холкы, әлеге мөнәсәбәтләрнең балага булган йогынтысы.

Гаиләнең социаль багланышлары: күршеләр, танышлар, баланың яшьтәшләре, педагоглар, тәрбиячеләр белән элемтәләре.

Торак.

Гаиләнең торак-көнкүреш шартлары:

гомуми һәм торак мәйданы; торакның кемнеке булуы һәм төзеклеге; санитар-гигиена торышы – яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнмәслек; көнкүреш һәм финанс шартлары турында өстәмә белешмәләр.

Баланың аерым бүлмәсе, карават, уеннар, дәресләр, уенчыклар, китаплар, көн режимы һәм туклану урыннары булуы.

Эш: кем эшли, эш булуы яки булмавы, эш режимы, эштәге үзгәрешләр эштә һәм моның балага ничек итеп йогынты ясавы.

Керем: җитәрлекме яки юкмы, балага бу ничек йогынты ясый, бала барлык кирәк-яраклар белән тәэмин ителгәнме (кием-салым, аяк киеме, йомшак инвентарь, уенчыклар, мәктәп-язу кирәк-яраклары җитәрлекме), махсус түгәрәкләр, мәктәпләр өчен түләү.

Яшәү урыны буенча ресурслар: белем бирү оешмаларының, мәдәният оешмаларының, медицина оешмасының файдалана алырлык булуы.

Нәтиҗәләр:

1. Нәрсә белән тәэмин итү таләп ителәчәген формалаштырырга (3 бүлек буенча – баланың ихтыяҗлары, гаилә һәм әйләнә-тирәлек факторлары) һәм моның өчен уллыкка (кызлыкка) алучыларга нәрсә эшләү (үзгәртү) таләп ителә.

2. Гаиләгә һәм балага өстәмә ярдәм кирәкме, аны кем бирәчәк.

Нәтиҗәләр: уллыкка (кызлыкка) алуның уңышлылыгын бәяләү:________________________________.

________________________________

Хисап төзегән затның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), имзасы

мөһер урыны

Раслыйм

________________________________ ____________ ________________________________

опека һәм попечительлек органы җитәкчесенең (имзасы) (фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта))

мөһер урыны ________________________________

**Искәрмәләр**:

1. Хисап төзегәндә конфиденциальлекне сакларга кирәк.
2. Чит ил гражданнары, Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, Россия Федерациясе гражданы булган баланы уллыкка (кызлыкка) алганда хисап тиешле йөкләмәләрне үз өстенә алган компетентлы орган бланкында әзерләнә. Хисапка хисап төзү мизгеленә баланың фотосурәтләре теркәлә.

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта**

Директорга (баш табибка) юллама биргән орган бланкы

____________________ ______________________________________
(адрес һәм телефон) (ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен медицина оешмасы атамасы____________N ___________ )

______________________________________
(Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта))

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала янына бару өчен**

**ЮЛЛАМА**

Бирелде______________________________________________________________,
(гражданнарның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта))
кандидатларга ______________________________________________________,
(гаиләгә урнаштыру формасына карап)
гражданнарга___________________________________________баланы барып карау өчен
(кандидатлар шул дәүләтнең гражданнары булып торган дәүләт исеме)
__________________________________________________________________
______________________________________________________________ өчен
(баланың фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта), туган елы)

уллыкка (кызлыкка) яки опекага (попечительлеккә) рәсмиләштерү)
(кирәклесе астына сызарга)

______________________ ____________ ____________________________
(юллама биргән орган җитәкчесенең (имзасы) (фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта))

мөһер урыны

Кабул ителгән карар турында
белешмәләр_____________________________________________.
(ризалык/баш тарту (сәбәпләрен күрсәтеп))

Дата____________________________________
(уллыкка (кызлыкка) алучыларга кандидатларның имзалары)

---

**Искәрмә**. Юллама шәхесне раслаучы документ күрсәткәндә һәм ун эш көне дәвамында гамәлдә була.

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта**

**Форма**

**Гаиләгә тәрбиягә тапшырылырга тиешле бала турында**
**МӘГЪЛҮМАТ**

Исеме________________________________Җенесе____________________________
Туган ае, елы____________________________________________________
Билгеләре______________________________________________________________
(күз төсе, чәч төсе)
Холык үзенчәлекләре__________________________________________________
Күз төсе__________________чәч төсе ________________________________
Этник килеп чыгышы_________________________________________________
Сәламәтлек торышы _____________________________________________________
Физик үсеше _____________________________________________________
Үсешен бәяләү (торышы)_______________________________________________
Акыл үсеше _____________________________________________________
Инвалидлык булуы (булмавы)________________________________________

Балигъ булмаган абыйлары һәм сеңелләре турында мәгълүмат:
Исеме__________________Туган елы______________________________________
Мәгълүматка баланың фотосурәте (яки аның электрон күчермәсе куела).
Гаиләгә урнаштыруның мөмкин булган
формалары______________________________________

_______________ ______________ ______________________________________
(вазыйфа) (имза) (фамилиясе, исеме һәм ата исеме (булган очракта))

мөһер урыны

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 12 нче кушымта**

**Форма**

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкының төбәк операторы функцияләре йөкләнгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы бланкы

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль банкта исәптә торучы балалар турында белешмәләр бирү турында**

## РӘСМИ МӨРӘҖӘГАТЬ

Уллыкка (кызлыкка) алуга, опекунлыкка (попечительлеккә) алуга кандидатлар(кандидат) өчен түбәндәгеләрне бирүегез турында (кирәкмәгәнен сызарга) үтенәбез: ______________________________

______________________________

(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)),

______________________________

шәхесне раслаучы документ, аның сериясе һәм номеры,

______________________________

гражданин (ирнеке дә, хатынныкы да) анкетасының номеры

Балалар турында федераль банкта исәптә торучы балалар турында һәм түбәндәге теләкләргә туры килә торган мәгълүматлар:

Җенесе________Яше: ____________ башлап_________яшькә кадәр

Сәламәтлек торышы______________________________

Кыяфәте: күз төсе__________________чәч төсе__________________,

______________________________ булган.

(гражданнар бара ала торган Россия Федерациясе субъектын күрсәтергә)

Башка таләпләр______________________________

www.usynovite.ru сайтында бала анкетасының web-номеры:

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкының төбәк операторы функцияләре йөкләнгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы җитәкчесе

________________ ______________________________

(имза) (Ф.И.А. (соңгысы - булган очракта)

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында төбәк белешмәләр банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 13 нче кушымта**

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министры

______________________________________________

кемнән:

______________________________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**ГАРИЗА**

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

________________________________________________________________

(хата төре)

Язылган:________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат: ____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегез турында сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

Телефон: ___________________________ e-mail: ______________________________

Дата _______________ Имза________________/_____________________________

Хезмәт билгеләре
Гариза алынды:
Дата:
алыну №:
Гаризаны кабул иткән затның фамилиясе, исеме, ата исеме һәм имзасы